**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 25 декабрендәге 4653 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 31 августындагы 4747 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августындагы 665 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарын (аңа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 21 июнендәге 505 номерлы, 2020 елның 31 гыйнварындагы 54 номерлы, 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы, 2021 елның 30 октябрендәге 1030 номерлы, 2022 елның 9 февралендәге 102 номерлы, 2022 елның 1 апрелендәге 304 номерлы, 2022 елның 20 июнендәге 587 номерлы, 2022 елның 14 сентябрендәге 1002 номерлы, 2023 елның 21 февралендәге 171 номерлы, 2024 елның 18 июнендәге 434 номерлы, 2024 елның 13 сентябрендәге 785 номерлы, 2025 елның 22 апрелендәге 256 номерлы, 2025 елның 22 сентябрендәге 720 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үтәү максатыннан, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 31 августындагы 4747 номерлы «Казан шәһәрендәге яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 24 июнендәге 2256 номерлы, 2024 елның 15 августындагы 3370 номерлы, 2025 елның 14 маендагы 1455 номерлы, 2025 елның 20 июнендәге 1864 номерлы, 2025 елның 12 сентябрендәге 2866 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымтада:

1.1.1. II бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

**«II. Яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү**

2.1. Яшьләр сәясәте оешмаларындагы физик культура хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче | Хореограф | 26 610 |

2.2. Яшьләр сәясәте оешмаларындагы мәгариф хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| Уку-укыту буенча беренче дәрәҗәдәге ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Уку-укыту бүлеге сәркатибе | 25 960 |
| Уку-укыту буенча икенче дәрәҗәдәге ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Режим буенча дежур | 26 090 |
| | Кече тәрбияче | |
| Педагогик хезмәткәр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Хезмәт инструкторы | 27 390 |
| | Физик культура буенча инструктор | |
| | Музыка җитәкчесе | |
| Икенче | Концертмейстер | 27 500 |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | |
| | Педагог-оештыручы | |
| | Социаль педагог | |
| | Тренер-укытучы | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче | Методист | 27 650 |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| | Тәрбияче | |
| | Өлкән тренер-укытучы | |
| | Педагог-психолог | |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| Дүртенче | Өлкән методист | 27 780 |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |
| | Өлкән тәрбияче | |
| Структур бүлекчә җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм балаларга өстәмә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган башка структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы) | 27 830 |
| Икенче | Балаларга белем бирү программасын һәм өстәмә белем бирү буенча мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган аерым структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 27 890 |

«Яшьләр белән эшләү белгече» һәм «яшьләр белән социаль эш алып бару белгече» вазифаларын башкаручы хезмәткәрләрнең төп оклады 27 500 сум тәшкил итә.

2.3. Яшьләр сәясәте оешмаларындагы медецина хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче | Диета буенча шәфкать туташы (диета буенча медицина хезмәткәре (ир-ат)) | 27 210 |
| Өченче | Шәфкать туташы (медицина хезмәткәре (ир-ат)) | 27 760 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медицина хезмәткәре (ир-ат)) | |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 32 090 |

Яшьләр сәясәте оешмаларының медицина хезмәткәрләре өчен төп окладка тармакның өстенлек коэффициенты кулланыла. Тармакның өстенлек коэффициенты зурлыгы 1,1 тәшкил итә.

Әлеге коэффициентны төп окладка карата куллану яңа төп оклад барлыкка китерә һәм компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгеләнгәндә исәпкә алына.

2.4. Яшьләр сәясәте оешмаларындагы мәдәният хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Вазифа атамасы** | **Айлык төп оклад күләме, сум** |
|---|---|
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Билет тикшерүче | 26 900 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 27 450 |
| Костюмнар бүлмәсе мөдире | |
| Мәдәни чараларны оештыручы | |
| Түгәрәк, һәвәскәр берләшмә, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе | |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 28 000 |
| Тавыш операторы | |
| Кинооператор | |
| Китапханә, музей һәм башка охшаш учреждениеләр һәм оешмалар мөхәррире | |
| Клуб эше методикасы буенча белгеч | |
| Ут буенча рәссам | |
| Рәссам-декоратор | |
| Рәссам-бизәүче | |
| Рәссам-фотограф | |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Мәдәният йорты (сарае), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗаты буенча фәнни-методик үзәк, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәният һәм ял итү) үзәге һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар бүлеге (секторы) мөдире | 29 320 |
| Тавыш режиссеры | |
| Куючы режиссер | |
| Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | |
| Массакүләм тамашалар режиссеры | |
| Сәнгать җитәкчесе | |

Яшьләр сәясәте оешмаларының мәдәният хезмәткәрләре өчен тармакның

төп окладына өстенлек коэффициенты кулланыла.

Тармакның өстенлек коэффициенты күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

- «Техник башкаручы һәм ярдәмче составтагы артист вазифалары» һөнәри квалификация төркеме буенча – 1,05;

- «Мәдәният, сәнгать һәм урта бүлек кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һәм «Мәдәният, сәнгать һәм әйдәп баручы бүлек кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркемнәре буенча – 1,12;

- «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкчелек составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме буенча – 1,25.

Әлеге коэффициентларны төп окладка карата куллану яңа төп оклад барлыкка китерә һәм компенсация һәм стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр билгеләнгәндә исәпкә алына»;

1.1.2. «Яшьләр сәясәте оешмасы җитәкчесенең, җитәкче урынбасарының һәм баш бухгалтерының хезмәт хакын билгеләү тәртибе» дигән VII бүлектә 16 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«16 таблица

**Яшьләр сәясәте оешмалары җитәкчеләренең төп окладлары күләмнәре**

| № т/б | Оешма төренең исеме/оешманың штат саны, берәмлекләрдә | Хезмәт өчен түләү төркеме | Җитәкченең оклады*, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | Яшьләр үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр, аны да кертеп | 1 | 38 720 |
| | 11 дән 30 га кадәр | 2 | 43 200 |
| | 31 дән 50 гә кадәр | 3 | 48 640 |
| | 51 дән 70 кә кадәр | 4 | 51 910 |
| | 71 дән 150 гә кадәр | 5 | 54 090 |
| | 151 дән алып | 6 | 60 740 |
| 2 | Сәламәтләндерү-ял оешмалары (лагерьлар) | | |
| | 10 га кадәр, аны да кертеп | 1 | 41 140 |
| | 11 дән алып | 2 | 44 170 |
| 3 | Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары | | |
| | 12 гә кадәр, аны да кертеп | 1 | 38 720 |
| | 13 тән 25 кә кадәр | 2 | 44 170 |
| | 26 дан 40 ка кадәр | 3 | 49 730 |
| | 41 дән 70 кә кадәр | 4 | 51 910 |
| | 71 дән 140 ка кадәр | 5 | 55 300 |
| | 141 дән алып | 6 | 80 470 |

| № т/б | Оешма төренең исеме/оешманың штат саны, берәмлекләрдә | Хезмәт өчен түләү төркеме | Җитәкченең оклады*, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 4 | Хәрби-патриотик эш һәм яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләү үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр, аны да кертеп | 1 | 32 670 |
| | 11 дән 20 гә кадәр | 2 | 42 830 |
| | 21 дән алып | 3 | 53 000 |
| 5 | Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре | | |
| | 10 га кадәр, аны да кертеп | 1 | 40 540 |
| | 11 дән 30 га кадәр | 2 | 46 460 |
| | 31 дән 50 гә кадәр | 3 | 47 670 |
| | 51 дән 70 кә кадәр | 4 | 48 880 |
| | 71 дән 90 га кадәр | 5 | 50 090 |
| | 91 дән алып | 6 | 51 300 |
| 6 | Балалар һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерүне, аларның ялын һәм эш белән тәэмин итүне оештыру үзәкләре | | |
| | 45 кә кадәр, аны да кертеп | 1 | 49 610 |
| | 46 дан 90 га кадәр | 2 | 54 450 |
| | 91 дән алып | 3 | 59 290 |
| 7 | Студентларның хезмәт отрядлары үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр, аны да кертеп | 1 | 47 430 |
| | 11 дән 30 га кадәр | 2 | 48 640 |
| | 31 дән алып | 3 | 49 850 |
| 8 | Балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр, аны да кертеп | 1 | 48 520 |
| | 10 нан 25 кә кадәр | 2 | 52 150 |
| | 26 дан алып | 3 | 55 780 |
| 9 | Балалар һәм балигъ булмаганнар өчен телефон аша ашыгыч психологик ярдәм үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр, аны да кертеп | 1 | 47 190 |
| | 11 дән 30 га кадәр | 2 | 52 030 |
| | 31 дән 50 гә кадәр | 3 | 56 870 |
| | 51 дән 70 кә кадәр | 4 | 61 710 |
| | 71 дән алып | 5 | 67 760 |
| 10 | Девиант тәртипле балалар өчен социаль тернәкләндерү үзәге | | |
| | 20 гә кадәр | 1 | 55 660 |
| | 21 дән 40 ка кадәр | 2 | 58 080 |
| | 41 дән 60 ка кадәр | 3 | 60 500 |
| | 61 дән алып | 4 | 62 920 |
| 11 | Яшьләргә ярдәм итү үзәкләре | | |
| | 12 гә кадәр, аны да кертеп | 1 | 38 720 |

| № т/б | Оешма төренең исеме/оешманың штат саны, берәмлекләрдә | Хезмәт өчен түләү төркеме | Җитәкченең оклады*, сумнарда |
|---|---|---|---|
| | 13 тән 25 кә кадәр | 2 | 44 170 |
| | 26 дан 40 ка кадәр | 3 | 49 730 |
| | 41 дән 70 кә кадәр | 4 | 51 910 |
| | 71 дән 140 ка кадәр | 5 | 55 300 |
| | 141 дән алып | 6 | 80 470 |
| 12 | Республиканың яшьләр, инновацион һәм профилактик программалар үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр, аны да кертеп | 1 | 38 720 |
| | 11 дән 30 га кадәр | 2 | 43 200 |
| | 31 дән 50 гә кадәр | 3 | 48 640 |
| | 51 дән 70 кә кадәр | 4 | 51 910 |
| | 71 дән 150 гә кадәр | 5 | 54 090 |
| | 151 дән алып | 6 | 60 740» |

1.2. 2 номерлы кушымтада II бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

**«II. Яшьләр сәясәте оешмаларындагы гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең, гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладын билгеләү**

2.1. Яшьләр сәясәте оешмаларындагы гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 25 650 |
| Икенче | 25 870 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 26 030 |
| Икенче | 26 220 |
| Өченче | 26 420 |
| Дүртенче | 27 010 |

2.2. Яшьләр сәясәте оешмаларындагы гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Айлык төп оклад күләме, сум** |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 25 650 |
| Икенче | 25 870 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 26 030 |
| Икенче | 26 220 |
| Өченче | 26 420 |
| Дүртенче | 26 660 |
| Бишенче | 26 870 |
| «Өченче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 27 080 |
| Икенче | 27 300 |
| Өченче | 27 560 |
| Дүртенче | 27 780 |
| Бишенче | 28 000 |
| «Дүртенче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 29 040 |
| Икенче | 29 260 |
| Өченче | 29 480 |

2.3. Хезмәткәр вазифасының һәм һөнәренең гомумтармак эшче һөнәрләре һәм гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

2.4. Икенче эш урыны буенча эшләүче, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яки башкарылган эш күләменнән чыгып башкарыла. Төп вазифа, шулай ук берьюлы башкару тәртибендә билгеләнгән вазифа буенча хезмәт хакы күләмен билгеләү һәр вазифа буенча аерым башкарыла».

2. Әлеге карарның йогынтысы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**